**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урсай авылы № 95 17 апрель 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә

Урсай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советының 2012 елның 23 гыйнварындагы 36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә: (24.09.2012 №55, 05.08.2013 №74, 22.10.2014 №111, 30.09.2015 №6, 15.11.2016 №44 карарлар редакциясендә),

1.1. 6 статьяның 1 өлешендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;».

б) 3 нче өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«14) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;».

1.2. 7 статьяның 1 өлешендә:

2 пункт гамәлдән чыккан дип таныргa;

б) дополнить пунктом 15 следующего содержания:

11.10. Инвалидларның, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлеге чикле затларның физик культурасын һәм спортын, адаптив физик культурасын һәм адаптив спортын үстерүгә ярдәм итә;

1.3. 11 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар;».

1.3. 20 нче статьяда:

Исемен түбәндәге редакциядә бирергә:

«20 статья. Халык тыңлаулары, җәмәгать фикер алышулары»;

б) 3 нче өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Халык тыңлауларына чыгарылырга тиеш:

1) җирлек уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, Уставка үзгәрешләр

бары тик җирле әһәмияттәге мәсьәләләр Уставында беркетелә торган мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга туры китерү максатларында гына кертелә торган очраклардан тыш;

2) бюджеты һәм аның үтәлеше турында хисап проекты;

3) җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә җирлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында белдерелгән җирлек халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 10 пунктчаны өстәргә:

«11. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау кагыйдәләре проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тота торган проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә яисә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына, капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен үзгәртү мәсьәләләренә, җирдән файдалануның расланган кагыйдәләре булмаганда һәм төзелеш корылмаларын файдалануның башка төрен үзгәртү мәсьәләләренә җәмәгатьчелек фикер алышу яисә гавами тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе җирлек Советының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә.».

1.4. 29 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:

«29 статья. Җирлек Советы депутаты, җирлек җирле үзидарәсенең сайланулы органы әгъзасы, җирлек җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи заты статусы

1. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре аны сайлаган көннән башлана һәм яңа чакырылыш җирлек Советы эшли башлаган көннән туктатыла.

2. Җирлек Советы депутаты, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, депутат эшчәнлеген төп эш урыны буенча хезмәт һәм хезмәт бурычларын үтәү белән берләштереп, үз нигезендәге нигездә эшли.

3. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының, муниципаль вазыйфаны биләүче башка затның вәкаләтләре «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ

Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәре), акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07.05 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.

Җирлек Советы депутатлары, җирлекнең җирле үзидарә сайланулы органы әгъзалары, җирлек җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә бурычлы:

- үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә тапшырырга;

- Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мондый конфликтны булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә.

4. Җирлек Советы депутатына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав, җирлек Советы карарлары нигезендә үз вәкаләтләрен тоткарлыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин ителә.

5. Җирлек Советы депутаты җирлек Советы тарафыннан раслана торган депутат этикасы кагыйдәләрен үтәргә тиеш, алар шул исәптән депутатның түбәндәге йөкләмәләрен булырга тиеш:

1) шәхсән яисә аның якын туганнарына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен депутат статусыннан файдаланмау;

2) депутат бурычларын объектив башкаруда шик тудырырлык үз-үзеңне тотыштан тыелырга, шулай ук аның абруена яисә җирлек Советы абруена зыян китерергә сәләтле конфликтлы хәлләрдән качарга;

3) мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү куркынычы булганда - шәхси кызыксыну депутат бурычларын объектив үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вәзгыять, - бу хакта җирлек Советына хәбәр итәргә һәм аның әлеге конфликтны булдырмауга яисә җайга салуга юнәлдерелгән карарын үтәргә;

4) җирлек Советында билгеләнгән гавами чыгышлар кагыйдәләрен үтәргә;

5) депутат эшчәнлегенә бәйле булмаган максатларда конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән, депутат вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган белешмәләрне фаш итмәскә һәм файдаланмаска;

6) физик һәм юридик затлардан депутат бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссуда, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләүләр) алынмаска.

6. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерциячел оешма идарәсендә яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш) катнашырга, федераль законнарда каралган очраклардан һәм, оешма белән идарә итүдә катнашу җирле үзидарә органы исеменнән Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш;

2) укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән кала, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Бу очракта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яки Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, укыту эшчәнлеге, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек чит дәүләт, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына финанслана алмый;

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яки Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, коммерциягә нигезләнмәгән, дәүләтнеке булмаган чит ил оешмаларының идарә органнары, попечительлек һәм күзәтчелек советлары, башка органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эш итүче структур бүлекчәләре составына керергә».

7. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты карары буенча уздырыла.

8. Әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә уздырылган тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны тыю турында» 07.2013 № 79-ФЗ Федераль законда, дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 03.12.2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, җирле үзидарә органына депутат, җирле үзидарә органына вакытыннан алда тавыш бирү вәкаләтләрен кабул итү турында гаризасы белән Татарстан Республикасы Президенты мөрәҗәгать итә.».

1.5. 32 нче статьяда:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5) җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау;»;

түбәндәге эчтәлекле 4.6 пунктны өстәргә:

«35) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау.».

1.6. 39 статья түбәндәге эчтәлекле 7 өлешне өстәргә:

«7. «Татарстан Республикасы Президенты депутатның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, әлеге гариза кергән көн вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн булып тора»;

1.7. 42 статьяның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 20120 елның 3 декабреннән 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категорияләрдәге затларның счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, Россия Федерациясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акча чаралары яки кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маеннан 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш.

1.8. 47 нче статьяда:

а) 1 өлешнең 5 пунктындагы унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнаша;»;

б) 1 өлешнең 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац өстәргә:

11.10. Инвалидларның, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлеге чикле затларның физик культурасын һәм спортын, адаптив физик культурасын һәм адаптив спортын үстерүгә ярдәм итә;

1.9. 65 нче статьяда:

б) 3 нче өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган, гамәлгә куючысы җирлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.»;

б) 10 нче өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«10. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән, Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда кертелергә тиеш.».

1.10. 74 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:

«74 статья. Җирлек гражданнарының үзара салым акчалары

1. Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен гамәлгә ашырыла торган бер тапкыр түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләүләр күләме, саны җирлек составына керүче гражданнарның гомуми

санының (җирлек составына керүче торак пункт) 30 процентыннан артыграк була алмаган һәм алар өчен түләү күләме киметелергә мөмкин булган аерым категорияләреннән тыш, җирлек халкы өчен (җирлек составына керә торган торак пункт) абсолют зурлыкта тигез дип билгеләнә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарның бер тапкыр бирелә торган түләүләрен кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә.».

1.11. 79 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлек уставы проекты, җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, җирлек Уставын кабул итү турындагы мәсьәләне карау көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында җирлек Уставы проектында күрсәтелгән Устав проекты, күрсәтелгән муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибен бер үк вакытта бастырып чыгару (халыкка җиткерү) белән рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук җирлек Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки Татарстан Республикасы законнарының нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында үтәү рәвешендә үзгәрешләр кертелгәндә гражданнарның шул хакта фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.».

1.12. 81 нче статьяда:

а) 2 һәм 3 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлек уставы, җирлек Советының әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карары, муниципаль берәмлекнең контроль органын булдыруны күздә тоткан үзгәрешләр, аларны дәүләт теркәвенә алганнан соң рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә. Җирлек башлыгы хәлиткеч тавыш хокукына ия җирлек Советы рәисе вәкаләтләрен башкарган очракта, җирлек башлыгының тавышы җирлек Уставы, җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт кабул ителгәндә җирлек Советы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.

3. Җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртә торган әлеге Уставка кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү (Уставны федераль законнарга туры китерү очракларыннан, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлау вәкаләтләре, вәкаләтләре чоры, тәртибе үзгәрүдән тыш) күрсәтелгән вәкаләтләр һәм өстәмәләр әлеге Уставка өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт кабул иткән җирлек Советының вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш өстәргә:

«3.1. Әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белән кертелә, ул рәсмиләштерелергә мөмкин:

1) җирлек Советы рәисе һәм аның башлыгы йә җирлек Советы рәисе вәкаләтләрен башкаручы бердәй җирлек башлыгы тарафыннан имзаланган җирлек Советы карары;

2) җирлек Советы кабул иткән һәм җирлек башлыгы кул куйган аерым норматив хокукый акт. Бу очракта әлеге хокукый актта җирлек Советының аны кабул итү турындагы карарының реквизитлары күрсәтелә. Җирлек Советының мондый карарына шушы Уставка кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр үз көченә керүе турында күчеш нигезләмәләрен һәм (яисә) нормаларын кертү рөхсәт ителми.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 5 һәм 6 өлешләр өстәргә:

«5. Җирлек уставын федераль канунга, Татарстан Республикасы законына туры китерү әлеге закон актларында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла. Федераль законда, Татарстан Республикасы законында күрсәтелгән срок билгеләнмәгән очракта, җирлек уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү срогы тиешле федераль закон, Татарстан Республикасы законы үз көченә керү датасын, җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектын гавами тыңлауларда рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм фикер алышу зарурлыгын, аның буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу, җирлек Советы утырышларының чиратлылыгын, мондый муниципаль хокукый актны дәүләт теркәве һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) срокларын исәпкә алып билгеләнә һәм, кагыйдә буларак, алты айдан артмаска тиеш.

6. Әлеге Уставны әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт белән яңа редакциядә кую рөхсәт ителми. Бу очракта яңа Устав кабул ителә, ә җирлекнең элек гамәлдә булган Уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актлар яңа Устав үз көченә кергән көннән үз көчләрен югалткан дип таныла.».

2. Әлеге карарның 1.1 пунктының дүртенче һәм бишенче абзацлары, 1.8 пунктының икенче һәм өченче абзацлары дәүләт теркәвенә алынганнан соң, әмма 2019 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт тарафыннан теркәү уздыру өчен юлларга.

4. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм түбәндәге веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http:/ aznakyevo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.А. Абдуллин